# OUTSTANDING SCHOLAR OF THE KAZAN SCHOOL OF LINGUISTICS: KLARA ZINNATULLINA

**Chulpan Mukharramovna Kharisova,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russia,
c.harisova@yandex.ru.



**ZINNATULLINA KLARA ZIEVNA** (1935-2007) was a linguist, Candidate of Philology (1968), laureate of the State Prize of the Republic of Tatarstan (1994), “Excellent Teacher of the Russian Federation”, Honorary Worker of Higher Education of the Russian Federation.

Upon graduation from Kazan State University (1958) she was a teacher of the Russian language and literature in a secondary school in Perm. In1962, she moved to Kazan and in 1965, she became a postgraduate student at the Department of Tatar Philology of Kazan Pedagogical University; in 1968, she completed her PhD thesis, and worked, for many years, as an associate professor. In 1997, she became a professor. From 1996, she was a dean of the Faculty of Tatar Philology at KSPU.

Her scientific works are devoted to Tatar linguistics and comparative grammar of the Tatar and Russian languages. She is the author of textbooks, manuals and syllabi on the Tatar language for universities and secondary schools.

**ЗИННӘТУЛЛИНА КЛАРА ЗЫЯ кызы** (1935-2007) − тел белгече, филология фәннәре кандидаты (1968), ТРның фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясе лауреаты (1994), РФнең мәгариф отличнигы, РФнең югары уку йортлары мактаулы хезмәткәре.

Казан дәүләт университетын тәмамлагач (1958), Пермь шәһәре урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укытучысы. 1962 елдан Казанда, 1965 елдан Казан педагогия университетының татар теле белеме кафедрасында: аспирантурада укый, 1968 елда «Татар телендә юнәлеш системасы» темасына кандидатлык диссертациясен яклый, күп еллар доцент булып эшли, 1997 елдан профессор. 1996-2002 елларда КДПУның татар филологиясе факультеты деканы. Фәнни хезмәтләре татар теле белеменә, татар һәм рус телләренең чагыштырма грамматикасына карый. Югары уку йортлары һәм урта мәктәпләр өчен татар теле дәреслекләре, уку кулланмалары һәм программалары авторы.

**ЗИННАТУЛЛИНА КЛАРА ЗИЕВНА** (1935-2007) − языковед, кандидат филологических наук (1968), лауреат Государственной премии РТ в области науки и техники (1994), отличник образования РФ, почетный работник высшего образования РФ.

После окончания Казанского государственного университета (1958) преподавала русский язык и литературу в средней школе г. Перми. С 1962 года в Казани, с 1965 г. аспирант кафедры татарского языкознания Казанского педагогического университета. В 1968 г. защитила кандидатскую диссертацию на тему «Залоги глагола в современном татарском литературном языке». В последующие годы работала доцентом, с 1997 года профессор. В 1996-2002 гг. декан факультета татарской филологии Казанского государственного педагогического университета. Научные труды по татарскому языкознанию, сравнительной грамматике татарского и русского языков. Автор учебников, учебных пособий и программ по татарскому языку для вузов и средних школ.

They say, the man goes away but his song leaves. For sure, 'his song' means his good deeds, words and works. We are going to tell about one of such people, Klara Ziatdinovna Zinnatullina, an outstanding scholar, who did a lot for Tatar Philology. She was a Candidate of Philology, Professor, Honoured Worker of Higher Education of the Russian Federation, who was awarded a medal "Veteran of Work". She is known for her fruitful work and creative activity at the former Kazan State Pedagogical Institute (later – University), where she trained future teachers all her life.

Klara khanum was born in the Aktanysh district of the Republic of Tatarstan. Her childhood coincided with the Great Patriotic War. As a person, who experienced all the hardships of that period, Klara Zievna remembered the post-war years as difficult and tragic beyond words. However, her desire to study was so strong that her parents were ready to help her even at the time when study-for-fee form of education was popular at schools, institutes and universities. She used to tell her colleagues about those unforgettable events.

Nature blessed her with beautiful features of character and appearance. Coming from one of the southern regions of the Republic of Tatarstan, she had dark eyes and curly black hair. Indeed, a straight nose and long curving black eyelashes added to her beauty and charm. As a teacher, she entered the classroom with a radiant smile and a sure step, which excited her students' admiration. We knew her as a careful, quiet, regardful, and intelligent person, ready to help anyone who asked for advice. From her life experience, she knew all about the relationships between parents and children, adults and teenagers, and was able to explain these things to the youth.

In 1953, after leaving the Aktanysh school with a gold medal (the first gold medal in the district!), K.Zinnatullina entered Kazan State University named after V.I.Ulyanov-Lenin. She studied at the History and Philology Department and got a higher education.

She remembered the companionship with students from other European socialistic countries, especially from Hungary and Romania, who studied in Kazan in 1950-1960; they met a few times many years after and said they missed Kazan and Tatarstan.

On graduating from the university, she married Nazif Khatmullovich, her countryman and classmate, who was a graduate of the Mechanical Faculty of the Kazan Institute of Chemistry and Technology named after S.M.Kirov and got a diploma in Engineering. As young specialists, they were sent to Perm, where they lived for several years. Klara Zievna's teacher, Professor M.Z.Zakiev suggested that she do a postgraduate course, and she came back to Kazan in 1961. Soon her supervisor was appointed a Vice Rector for Research and the young postgraduate student came to work at his Department. And since that time Klara Zievna's work was connected with the Pedagogical Institute. She began her research into "Voice in the Tatar language", which had not been studied before in a monographic aspect. Klara Zievna successfully completed her PhD thesis in 1968 and her official opponent was the outstanding turkologist, A.A.Yuldashev, who highly appreciated her work and said it was "a great step forward in Tatar verb studies".

K.Z.Zinnatullina was the first to study the voice, one of the universal grammatical categories, in a monographic aspect. She thoroughly explored the history of verb studies, identified specific forms of five different verb voices, and outlined the role of voice suffixes in word formation. This voice category holds its rightful place in the verb system of the Tatar language: even today, linguists refer to this work by Klara Zinnatullina. Later, in 1969, it was published as a monograph "Verb Voices in the Modern Tatar Literary Language" [1].

The Tatar Philology Department, headed by M.Z.Zakiev in 70-80s, published monographs and collections of scientific papers devoted to the Tatar-Russian bilingualism, the Tatar language teaching issues, and relevant aspects of Tatar Philology. Certain publications were released biannually and aroused great interest in the academic community. As a science editor, Klara Zievna made a great contribution to that success, she edited scholars and postgraduates' manuscripts in Tatar and Russian and helped to prepare them for publication. In this way, young researchers became renowned as highly professional scholars fluent in two languages.

Klara Zievna researched Tatar syntax, particularly, complex sentence syntax: she taught such special courses as "Complex sentences at schools and colleges", "Grammar categories of Tatar verbs", and "Polynomial complex sentences in the Tatar and Russian languages".

The textbook *Modern Tatar Literary Language Morphology* for students and teachers was published together with Associate Professors Z.M.Va-

liullina and M.A.Sagitov in 1972 [2]. Its "Verb" chapter was written by Klara Zievna in an accessible language, it was meant for students, teachers and those who were interested in the language. The book has been a source for Tatar morphology learners for many years.

It is known that the comparative-typological studies of the Tatar and Russian languages became very popular in the 1970-1980s. The syllabi of typology courses (Russian and native languages) for Teacher Training Institutes were elaborated with the participation of academician M.Z.Zakiev [3, 4], they were published in Moscow and Leningrad and were in high demand throughout the USSR.

Z.M.Valiullina's monograph *Comparative Grammar of the Russian and Tatar Languages* was published in 1983 [5]. The author explored the issues of word-formation and morphology making valuable conclusions for teaching practices, as the comparison of Tatar and Russian syntax grew in importance. Eventually, M.Z.Zakiev, K.Z.Zinnatullina and F.S.Safiullina's monograph *Comparative Syntax of the Russian and Tatar Languages*, consisting of three chapters, was published in 1977 [6]. The book contains a thorough comparison of the interrelated Russian and Tatar syntax systems and identifies their common and distinctive features. A great part of this work, which has not lost its relevance for the students, postgraduates, teachers and scholars, was written by K.Z.Zinnatullina. These materials are based on her experience in teaching Tatar syntax to students.

At the beginning of the 1990s, an editorial board was formed at G.Ibragimov Institute Language, Literature and History with the aim to elaborate the grammar of modern Tatar literary language. Together with other scholars of our Republic, K.Z.Zinnatullina participated in this project. This group of scholars conducted research into Tatar phonetics, word-formation, morphology and syntax. Klara Zievna was engaged in the elaboration of the greater part of the chapter devoted to morphology. Extensive factual material was systematized and thoroughly elucidated in the context of the latest developments in linguistics. She, as usual, did her best in editing the text of this voluminous higher level grammar. Since 1993, the three-volume Tatar grammar has been publish more than once, first in Russian, then in Tatar. K.Zinnatullina took pains to edit all these publications. For that work, this group of scholars, K.Zinnatullina among them, were granted the State Prize of the Republic of Tatarstan in Science and Technology in 1994.

Such grammatical phenomena as adjectives, pronouns, verbs and adverbs, as well as the mood and the gerund were elucidated by the scholar through the inner language features in the context of the recent developments in linguistics [7]. She conducted a functional and semantic analysis of the parts of speech, providing it with literary-illustrative materials.

Klara Zievna was a consultor and a helping hand for teachers of language and literature both in the Republic and beyond. She gladly and willingly shared her rich methodological experience with school teachers and young researchers. In 1991, she and other authors completed the Tatar language textbooks and syllabi for the fifth and sixth forms of Tatar schools and for Tatar pupils of Russian schools [8, 9, 10]. Along with these activities, she taught many courses at the Institute of Continuing Education; helped young researchers and postgraduates by writing reviews of their theses; taught students general and special courses in modern Tatar literary language syntax, and supervised the degree works. The language lessons, which would have been dull and boring, but for Klara Zievna' style of teaching, kindled her students' interest in a sentence analysis and love for philology as an area of science.

From 1970, Klara Zievna worked as a deputy dean for extramural studies and in 1995 she was elected Dean of the Tatar Philology Faculty. It was during that time that the Tatar language as a students' major course enjoyed the greatest popularity, with three or four student groups each year, obviously owing to her efforts, as well as the fact that our language was introduced to other nations.

In spite of her busy working schedule, Klara Zievna found time to do sports in the park near the Palace of Chemists in Kazan, and her healthy lifestyle was an example for others. She found time and opportunity to enjoy camping out, knew all the recent developments in the sphere of literature and arts, and communicated with writers. She believed that every human being should be an all-round person.

People are remembered for their good deeds. K. Zinnatullina's work is continued in her students and children… Our honoured and estimable teacher, Candidate of Philology, Prof. Klara Zinnatullina made great contributions to the Kazan School of Linguistics and Linguodidactics. Her scientific works are still used in Turkic philological research and education.

**References**

1. *Zinnatullina K.Z.* Zalogi glagola v sovremennom tatarskom literaturnom yazyke. Kazan'. Tatar. kn. izd-vo, 1969. 195 s. (in Russian)
2. *Väliullina Z.M., Zinnätullina K.Z., Sägyytov M.Ä.* Khäzerge tatar ädäbi tele morfologiyase. Kazan, 1972. 210 b. (in Tatar)
3. *Zakiev M.Z., Zinnatullina K.Z.* Programma pedagogicheskikh institutov. Sopostavitel'naya tipologiya russkogo i rodnogo yazykov. M.: Prosveshchenie, 1978; 1980. 24 s. (in Russian)
4. *Zakiev M.Z., Zinnatullina K.Z.* Programma po sopostavitel'noy tipologii russkogo i rodnogo yazykov dlya pedvuzov (dopolnennoe i pererabotannoe izdanie) /Minpros SSSR, Leningrad, 1985. 20 s. (in Russian)
5. *Valiullina Z.M.* Sopostavitel'naya grammatika russkogo i tatarskogo yazykov. Kazan': Tat. kn. izd-vo, 1983. 210 s. (in Russian)
6. *Zakiev M.Z., Zinnatullina K.Z., Ibragimov S.M.* Sopostavitel'nyy sintaksis russkogo i tatarskogo yazykov. Uchebnoe posobie dlya studentov i uchiteley. Chast' III. Slozhnoe predlozhenie. Kazan', 1977. 85 b. (in Russian)
7. *Zinnatullina K.Z.* Imya prilagatel'noe. Zalogi glagola. Deeprichastie. Mestoimenie. Narechie // Tatarskaya grammatika. Kazan', Tat. kn. izd-vo, 1993. S. 64-67; 163-184; 223-230; 252-263; 288-292. (in Russian)
8. *Yusupov R.A., Zinnätullina K.Z., Gayfullina T.M.* Tatar tele. Tatar mäktäplärenen̡ 5 nche klassy öchen däreslek. Kazan: Mägarif, 1991; 1995; 2000. 167 b. (in Tatar)
9. *Tumasheva D.G., Zinnätullina K.Z., Miftakhov B.M.* Tatar tele. Tatar mäktäplärenen̡ 6 nchy klassy öchen däreslek. Kazan: Mägarif, 1991; 1995; 2001. 304 b. (in Tatar)
10. Tatar mäktäbenen̡ 5-11 nche syynyflarynda ukuchylar öchen tatar tele programmasy. Kazan: Mägarif, 1996. 50 b. (in Tatar)

# КАЗАН ЛИНГВИСТИКА МӘКТӘБЕНЕҢ КҮРЕНЕКЛЕ ГАЛИМЕ КЛАРА ЗИННӘТУЛЛИНА ЭШЧӘНЛЕГЕ

**Чулпан Мөхәррәм кызы Харисова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
c.harisova@yandex.ru.

Кеше китә – җыры кала, диләр халыкта. Җыры дигәндә, аның башкарган игелекле эшгамәлләре, әйткән сүзләре, язган хезмәтләре күзалдында тотыла, мөгаен. Сүзебез шундыйларның берсе, татар теле белеме өлкәсендә күп хезмәтләр куйган күренекле галим, филология фәннәре кандидаты, профессор, Россия Федерациясенең мәгариф отличнигы, Россия Федерациясенең югары уку йортлары мактаулы хезмәткәре, «Хезмәт ветераны» медале белән бүләкләнгән Клара Зыятдин кызы Зиннәтуллина турында. Ул гомере буе элеккеге Казан дәүләт педагогика институтында (соңыннан – университетында) эшләде һәм иҗат итте.

Клара ханым Татарстан Республикасының Актаныш районында туып үсә. Бала чагы Бөек Ватан сугышы елларына туры килә. Ул чорның авырлыгын үз җилкәсендә татыган кеше буларак, Клара Зиевна сугыштан соңгы елларның әйтеп бетерә алмаслык катлаулы һәм фаҗигале булуын искә ала иде. Мәктәптә һәм институтларда, университетларда түләүле уку формасы хөкем сөргән заманда да яшьләрнең, шул исәптән үзенең дә белем алуга омтылышы һәм теләгенең көчле булуы, эти-әниләренең дә аның фикеренә каршы булмавы турында сагынып сөйләве гаҗәпләндерә иде. Күрәсең, гомер буе онытылмаслык булып күңеленә уелып калган вакыйгаларны яшь хезмәттәшләренә җиткерергә теләгән.

Табигать укытучыбызга матур сыйфатларны мул бүләк иткән. Татарстанның көньяк районнарының берсеннән килгән кеше буларак, ул кара күзле, кара бөдрә чәчле, шуның белән бергә төз борын, очлары бөгелеп килгән озын куе кара керфекләр аңа тагын да гүзәллек һәм мөлаемлылык өстиләр. Ягымлы, көләч елмаюлы йөз һәм җитез адымнар белән дәрескә кереп килүче укытучы үзенең шәкертләрендә соклану хисләре генә уята иде. Без аны холык-фигыле белән салмак һәм ипле, олыларга һәм кечеләргә игътибарлы һәм ихтирамлы, тормышта акыллы, ярдәмчел һәм кирәкле урында төпле киңәше белән һәркемгә булышырга әзер торган кеше буларак беләбез.

Үзенең тормыш тәҗрибәсеннән чыгып, ул аталар һәм балалар, олылар һәм кечеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә дә үз фикерен белдерә, шуны яшьләр колагына сала белү осталыгына ия иде.

Актаныш урта мәктәбен алтын медальгә (районда беренче булып!) тәмамлагач, 1953 елны К.Зиннәтуллина В.И.Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетына юл тота. Анда, тарих-филология факультетында укып, югары белем ала.

1950-1960 елларда Казанда Европаның кайбер социалистик илләреннән, аерым алганда, Венгриядән һәм Румыниядән килеп укыган студентлар белән аралашуларын, дистә еллар узгач та, кайберләре белән очрашып, Казанны – Татарстанны сагынып искә алуларын хәтерендә яңарта иде.

Университетны тәмамлаганда, алар якташы һәм сыйныфташы, С.М.Киров исемендәге Казан химия-технология институтының механика факультетын кызыл дипломга тәмамлап, инженер дипломы алган Назиф Хәтмулла улы белән гаилә корып җибәрәләр. Яшь белгечләр буларак, Пермь шәһәренә җибәрелгәч, алар берничә ел шунда яшиләр. 1961 елда Казанга кайткач, Клара Зиевнаны остазы профессор М.З.Зәкиев үзенә аспирантурага чакыра. Озакламый аның җитәкчесен КДПИга фәнни эшләр буенча проректор итеп күчерәләр һәм яшь аспирант та аның кафедрасына эшкә килә. Шулай итеп, Клара Зиевнаның алдагы хезмәт юлы педагогика институты белән бәйләнә. Ул моңарчы монографик планда өйрәнелмәгән «Татар телендә юнәлеш системасы»н тикшерүгә алына. 1968 елда Клара Зиевна кандидатлык диссертациясен бик уңышлы яклый, рәсми оппоненты күренекле тюрколог Ә.Ә.Юлдашев аның хезмәтен: «татар фигылен өйрәнүдә зур адым», − дип югары бәяли.

К.З.Зиннәтуллина телебезгә хас булган универсаль грамматик категорияләрдән фигыль юнәлешләрен монографик планда беренче булып тикшереп, әһәмиятле гыйльми нәтиҗәләр ясый: аны өйрәнү тарихын бик тәфсилләп тикшерә, биш юнәлеш формасының төрле фигыльләрдә үзенчәлекле формаларын билгели, юнәлеш кушымчаларының сүз ясалышында тоткан урынын күрсәтә. Алга таба татар телендәге фигыльләр системасында әлеге категория үзенең лаеклы урынын таба: әле бүгенге көндә дә телче галимнәребез Клара Зиевнаның әлеге хезмәтенә таянып эшли. Озакламый ул, 1969 елда, «Залоги глагола в современном татарском литературном языке» исемле монография булып нәшер ителә [1].

Узган гасырның 70-80 елларында М.З.Зәкиев җитәкләгән татар теле белеме кафедрасы рус-татар икетеллелегенә, татар телен укыту проблемаларына, тел гыйлеменең актуаль мәсьәләләренә багышланган монографияләр һәм кафедра җыентыкларын төзеп бастыра. Кайбер хезмәтләр елына икешәр тапкыр басылып чыга һәм тиз арада таралып та бетә. Бу уңышта аларның фәнни мөхәррире Клара Зиевнаның өлеше зур була, чөнки ул, галимнәрнең һәм аспирантларның татарча һәм русча кульязмаларын фәнни яктан редакцияләп, тиешенчә формалаштыруда һәм матбугатка чыгаруда ярдәм итә. Яшь белгеч үзен ике телне дә камил дәрәҗәдә белүче, югары һөнәри осталыкка ия булган галим итеп таныта.

Бу елларда Клара Зиевна татар теленең синтаксисын, аерым алганда катлаулы җөмлә синтаксисын җентекләп тикшерә: студентларга лекцияләр уку белән беррәттән, «Мәктәптә һәм вузда иярченле кушма җөмләләр», «Татар фигыльләрендәге грамматик категорияләр», «Татар һәм рус телләрендә катлаулы кушма җөмләләр» исемле махсус курслар алып бара.

1972 елда доцентлар З.М.Вәлиуллина, М.Ә.Сәгыйтовлар белән берлектә студентлар һәм укытучылар өчен «Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе» исемле дәреслек басыла [2]. Андагы «Фигыль» бүлеген, студентларга, укытучыларга һәм, гомумән, тел белән кызыксынучыларга аңлаешлы итеп, Клара Зиевна яза. Әлеге китап бик озак еллар татар теленең морфологиясен өйрәнүчеләргә чыганак булып хезмәт итә.

Билгеле булганча, 1970-1980 елларда татар һәм рус телләрен чагыштырма-типологик планда өйрәнү юнәлеше киң колач ала. Шушы чорда академик М.З.Зәкиев белән берлектә педагогика институтлары өчен язылган рус теле белән туган телләрне типологик яктан чагыштыру программалары [3, 4] Мәскәүдә һәм Ленинградта басылып, бөтен СССРга тарала.

1983 елда З.М.Вәлиуллинаның «Сопоставительная грамматика русского и татарского языков» монографиясе дөнья күрә [5]. Автор анда ике телдәге сүз ясалышы һәм морфология проблемаларын киң яктырта, укытучылар өчен кирәкле һәм файдалы методик нәтиҗәләрен дә ясап бара. Татар теленең синтаксисын рус теле белән чагыштыру кирәклеге көн үзәгенә килеп

баса. Шул уңайдан 1977 елда М.З.Зәкиев, К.З.Зиннәтуллина һәм Ф.С.Сафиуллина тарафыннан язылган өч кисәктән торган «Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков» исемле күләмле монография дөнья күрә [6]. Анда үзара бәйләнештәге рус һәм татар телләренең синтаксик системалары җентекләп чагыштырыла, алардагы уртак һәм аермалы билгеләр ячтыртыла. Студентлар, аспирантлар, укытучылар һәм галимнәр өчен үзенең актуальлеген бүген дә югалтмаган бу хезмәтнең шактый өлеше К.З.Зиннәтуллина тарафыннан языла. Ул анда студентларга үзенең татар теле синтаксисын укыту тәҗрибәсеннән дә киң файдалана.

1990 еллар башында Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих (соңрак – сәнгать) институтында хәзерге татар әдәби теленең Академик грамматикасын төзү төркеме (редколлегиясе) оештырыла. Аның эшендә республиканың башка галимнәре белән бергә К.З.Зиннәтуллина да бик актив катнаша. Бер төркем галимнәр татар теленең фонетикасы, сүз ясалышы, морфологиясе һәм синтаксисы буенча академик басманы төзиләр. Морфология бүлегенең шактый гына өлешен Клара Зиевна яза. Анда бай фактик материал системага салына һәм тел белеменең соңгы казанышлары югарылыгыннан тәфсилләп яктыртыла. Саллы зур күләмле Академик грамматиканың текстын редакцияләүне дә ул һәрвакыттагыча бөтен осталыгын һәм белемен эшкә җигеп, җиренә җиткереп башкара. 1993 елдан башлап, башта рус телендә, аннары татар телендә өч томлы Татар грамматикасы басыла башлый. К.Зиевна һәр икесен төзү һәм эшкәртүдә якыннан торып катнаша, зур хезмәт куя. 1994 елда ул, шушы өлкәдәге эшчәнлеге өчен, бер төркем галимнәр белән бергә, Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Галимә тарафыннан татар грамматикасының II томында сыйфат, алмашлык, фигыль юнәлешләре, хәл фигыль һәм рәвеш сүз төркемнәре, телнең эчке үзенчәлекләре истә тотылып, тел белеме казанышлары югарылыгында тикшерелә [7]. Ул сүз төркемнәрен функциональ-семантик яссылыктан анализлый, әдәби-иллюстратив материаллар белән дәлилләп бара.

Клара Зиевна республикабызда һәм аннан читтә дә тел һәм әдәбият укытучыларының киңәшчесе, ярдәмчесе иде. Ул үзенең бай фәнни-методик тәҗрибәсен укытучылар һәм яшь галимнәр белән бик теләп уртаклаша. 1991 еллардан башлап татар мәктәпләренең 5-6нчы сыйныфларында, рус мәктәбендә укучы татар балалары өчен язылган татар теле дәреслеге авторларының һәм программаларының авторларыннан берсе ул була [8, 9, 10]. Шушы эшләр белән беррәттән, ул укытучыларның белемнәрен камилләштерү институтында күпсанлы курсларда укыта; яшь галим һәм аспирантларның кандидатлык һәм докторлык диссертацияләренә бәяләмәләр язу аша, аларга ярдәм итә; озак еллар дәвамында студентларга хәзерге татар әдәби теленең синтаксисы фәненнән гамәли дәресләр һәм махсус семинарлар алып бара, диплом эшләре яздыра. Бер караганда, коры һәм төссез булып тоелган тел дәресләре Клара Зиевнаның эш манерасы, җөмләләрне тикшерү барышында бирелгән өстәмә һәм кызыклы мәгълүматлар студентны мавыктырып кына калмый, бәлки тел фәненә җәлеп итә, аңа мәхәббәт тә уята ала иде.

1970 еллардан башлап, Клара Зиевна деканның читтән торып уку-укыту эшләре буенча урынбасары булып эшли һәм 1995 елда татар филологиясе факультетының деканы итеп сайлана. Нәкъ менә шушы елларда татар теле һәм әдәбияты белгечлеге буенча өчәр, хәтта дүртәр төркем студентлар кабул ителә һәм әлеге эштә, шулай ук телебезне башка милләт вәкилләренә өйрәтү башлаган елларда аның оештыру сәләте тагын ачык күренә.

Тынгысыз һәм киеренке хезмәттә булуына карамастан, Клара Зиевна Казанның Химиклар сарае янындагы паркта спорт һәм физкультура белән дә шөгыльләнергә вакыт таба, башкаларны сәламәт яшәү формасына өнди иде. Ул табигатьтә булырга, әдәбият-сәнгать өлкәсендәге яңалыклар белән танышырга, язучылар белән аралашып яшәргә мөмкинлек һәм вакыт тапты, кеше һәр яктан үсештә булырга тиеш дигән гыйбарәне дә истә тотып яшәде.

Кеше үзенең башкарган эшләре, кылган изге гамәлләре белән башкалар хәтерендә кала. Аның эше укучыларында, балаларында дәвам итә. Зур хөрмәткә һәм ихтирамга лаек укытучыбыз филология фәннәре кандидаты, профессор Клара Зиевна Зиннәтуллина Казан лингвистика һәм лингводидактика мәктәбендә якты эз калдырды. Аның тарафыннан иҗат ителгән фәнни хезмәтләр хәзерге вакытта да бөтен төрки тел белемендә киң танылa һәм фәнни кулланылышта йөри.

**Әдәбият**


1. *Зиннатуллина К.З.* Залоги глагола в современном татарском литературном языке. Казань. Татар. кн. изд-во, 1969. 195 с.
2. *Вәлиуллина З.М., Зиннәтуллина К.З., Сәгыйтов М.Ә.* Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. Казан, 1972. 210 б.
3. *Закиев М.З., Зиннатуллина К.З.* Программа педагогических институтов. Сопоставительная типология русского и родного языков. М.: Просвещение, 1978; 1980. 24 с.
4. *Закиев М.З., Зиннатуллина К.З.* Программа по сопоставительной типологии русского и родного языков для педвузов (дополненное и переработанное издание) / Минпрос СССР, Ленинград,1985. 20 с.
5. *Валиуллина З.М.* Сопоставительная грамматика русского и татарского языков. Казань: Тат. кн. изд-во, 1983. 210 с.
6. *Закиев М.З., Зиннатуллина К.З., Ибрагимов С.М.* Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков. Учебное пособие для студентов и учителей. Часть III. Сложное предложение. Казань, 1977. 85 б.
7. *Зиннатуллина К.З.* Имя прилагательное. Залоги глагола. Деепричастие. Местоимение. Наречие // Татарская грамматика. Казань, Тат. кн. изд-во, 1993. С. 64-67; 163-184; 223-230; 252-263; 288-292.
8. *Юсупов Р.А., Зиннәтуллина К.З., Гайфуллина Т.М.* Татар теле. Татар мәктәпләренең 5 нче классы өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 1991; 1995; 2000. 167 б.
9. *Тумашева Д.Г., Зиннәтуллина К.З., Мифтахов Б.М.* Татар теле. Татар мәктәпләренең 6 нчы классы өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 1991; 1995; 2001. 304 б.
10. Татар мәктәбенең 5-11 нче сыйныфларында укучылар өчен татар теле программасы. Казан: Мәгариф, 1996. 50 б.